Сәгыйдә Сәубанова
ЯКТЫЛЫК
НИЧЕК
ТАРАЛА

Сәмига Сәубанова

ЯКТЫЛЫК НИЧЕК ТАРАЛА

ӘКИЯТЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1997

ББК 84(Р-Тат)-5
С93

Кече һәм урта яшьтәге балаларга

Рәссамы В. Хәкимов

С $\frac{4803560201-087}{М132(03)-97}$ 76—97

ББК 84(Р-Тат)-5

ISBN 5–298–00887–9

© Татарстан китап нәшрияты, 1997

ЯКТЫЛЫК НИЧЕК ТАРАЛА

Борын-борын заманда бер кешенең бик күп байлыгы булган икән. Булуын булган, әмма сәламәтлеккә туймаган бу кеше. Ашаган ризыгының тәме, кигән киеменең куанычы, байлыгының рәхәте юк ди моның. Табиблар да аңа берничек тә ярдәм итә алмаганнар. Һәм ул, чарасыз калып, таң алдыннан Кояшка дәшкән:

— Мин үләрмен инде, хуш, бәхил бул! — дигән.

Кояш әлеге кешене бик кызганган.

— Мин сиңа булышырмын, — дигән ул. — Тик шартыма риза булырсыңмы? Сәламәтлек бик кыйбат тора. Түләргә хәлеңнән килерме?

— Ни теләсәң — шуны алырсың, — дигән әлеге кеше.

— Миңа байлык кирәкми, — дигән Кояш. — Миңа ярдәм кирәк.

— Хәлемнән килгән хәтле булышырмын, — дигән кеше.

— Җирдә бөтен төсләр дә бар — яшеле дә, зәңгәре дә, сарысы да, көрәне дә, хәтта карасы да. Ә менә кызыл төс юк. Мин шуны таратырга дип, җиргә якынайсам, утларым бүтән төсләрне дә көйдертеп алыр. Син миңа, бүтән төсләргә зыян китермичә генә кызыл төсне таратырга булыш.

Кеше риза булган. Кояш аның күңеленә ут салган. Бу ут-ялкын аның күңелен җылыткан һәм ул терелеп киткән. Аннан соң Кояшка биргән вәгъдәсен үтәргә керешкән. Ин элек Кояшка үре-

леп кызыл төсне алган да яшел урманга сипкән, әмма урман дөрләп яна башлаган. Ярый әле, яңгыр болыты килеп, яшенләп яңгыр явып үткән, югыйсә урманнан көл генә каласы булган. Яфрак, үлән асларында яңгырдан качып калган җиләкләр, чәчәкләр кып-кызыл булганнар. Аптыраган Адәм, һәм ул Кояштан алган нурны диңгез өстенә җилпегән, анда да ялкын кабынган. Ләкин диңгез дулкыннары ялкынга таралырга ирек бирмәгәннәр, шунда ук каплап киткәннәр. Аннан соң ялкынны яшел болынга сибеп караган – яңа гына сибәләп үткән яңгыр болынны юешләтеп үтмәсә, монда да эш харап буласы икән. Кешенең күңеле төшкән. Вәгъдәсен үтәргә кулыннан килми икән бит. Кояшка күтәрелеп караса, тегесе аңардан мыскыллап көлә генә, ди.

– Җирдә утны таратуның кирәк түгеллеген белмисеңме син, Адәм? – дигән ул. – Бөтен дөньяга ут каптыру өчен бер бөртек шырпы яисә бәләкәй генә очкын да җитә. Ә син уңга да, сулга да ут таратасың. Мин бит күңелеңдәге ялкынны кешеләргә тарат дидем.

Шуннан соң Кеше үз күңелендәге ялкынны бүтәннәргә өләшә башлаган. Хәле дә әйбәтләнгән.

Аңардан күреп бүтәннәр дә үз күңелләрендәге ялкынны бер-берсенә өләшә башлаганнар. Ныграк өләшкән саен, күбрәк яхшылык итәселәре килә башлаган, ди боларның. Ә яхшылык итү – үзеңдә булган күңел байлыгын бүтәннәр белән уртаклашу бит ул. Күңелләренә салынган ялкын иң зур байлыклары булган аларның. Алар шул ялкынны яктылык итеп бөтен дөньяга таратканнар. Үзләреннән соң балаларына, ә алары исә тагын үзләреннән туган балаларга бу эшне дәвам итәргә

васыять итеп калдырганнар. Арыган, хәлдән тайган чаклары да күп булган аларның. Чөнки Җир шарын яктыртып торуы җиңел эш булмаган. Әмма кешеләргә өләшкән яхшылыкларын искә төшерү белән бөтен арыганлыклары юкка чыга икән.

Армый-талмый, мәшәкатьсез, әмма бер куанычсыз яшәүгә караганда, әнә шулай арып-талып яктылык таратуны артыграк күрүче кешеләр яшәгәнгә күрә дә шундый матур булган ул безнең Җиребез.

БӨДЕРКӘЙ

Дымсу иңкүлектә Әнкә өянке кочагында иркәләнеп үсеп утырган Бөдеркәйгә кемдер эндәште:

— Исәннәрме, саулармы?

Бөдеркәй тирә-ягына каранды, берни күрмәде.

— Нәрсә, танымыйсыңмы әллә?

Бөдеркәй тавышның астан килгәнлеген абайлап алды, әмма үлән арасында кибеп-саргайган сынык ботактан башка берни дә күрмәде.

— Танымассың да, син бит әнә нинди, ә мин...

Эндәшүченең шул кипкән ботак икәнлеген шунда гына абайлады Бөдеркәй.

Тавыш таныш кебек тоелса да, Бөдеркәй аның белән кайчан сөйләшкәнен исенә төшерә алмады.

— Без икебез дә Әнкә өянкенең балалары...

Бөдеркәйнең йөзендә куаныч балкыды.

— Ә-ә... Әйе, әйе... Без синең белән икебез бер көнне тишелеп чыккан идек... Әнкә өянке икебезнең дә үз янында үсүен теләгән иде... Аннан соң син юкка чыктың... Нәрсә булды, кайларда йөрдең, нигә шушындый хәлдә калдың?



...Әйе, алар бер көнне тишелеп чыкканнар иде. Икесе бергә кояшка күтәрелделәр. Икесе бергә бөдрәләнеп-бөдрәләнеп бөрегә төренделәр. Әмма аларның берсе икенчесенең матурлыгыннан сөенә-сөенә яфракларын лепер-лепер китерсә, икенчесе бу матурлыклардан ямь тапмады. Ул күршесеннән зарланырга, аны төрлечә каралтырга, ямьсезләргә тырышып яла яга башлады.

— Миңа дым җитми, бөтенесен дә Бөдеркәй берүзе суырып бетерә, — диде.

Якын-тирәдәге таллар-өянкеләр аны яклап бер сүз дә дәшмәделәр, бары тик башларын гына чайкадылар. Аны үзара Киребеткән дип йөртә башладылар. Киребеткәнгә әйтсәң ни, әйтмәсәң ни, файдасы юклыгын аңладылар.

Киребеткән бер яктан Бөдеркәйнең үзе кебек үк матур булуын күтәрә алмады, икенче яктан, үзенә теләктәш таба алмауга ачуы килде, шул сәбәпле кипте, корыды, бөреләнә башлаган алкалары көл кебек җилгә сибелде, ә үзе шәрә ботакка әверелде.

Әмма барыбер сабак ала белмәде, гаепне Бөдеркәйгә сылтады:

— Миңа төшәсе яктыны Бөдеркәй каплый, шуңа үсә алмыйм, аны йолкып атарга кирәк, — дип, Җилне котырта башлады.

Җилнең Киребеткәнгә күптән ачуы килеп йөри иде, бу юлы исә түзеп тора алмады, Киребеткәннең үзен йолкып атты да әллә кая очыртып алып та китте.

Ниләр генә күрмәде, кайларда гына булмады Киребеткән. Шулай шактый азапланды бу. Шуннан соң инде акылга утыргандыр, бүтән алай итмәс дип, Җил аны кире элекке урынына илтеп

куйды. Бөдеркәй тагын да матуррак булып үскән иде.

Моны күреп, Киребеткән көнләшүеннән нишләргә дә белмәде. Тик моны сиздермәде, үзенең ниләр күрүен дә әйтмәде.

— Сине әни ныграк яратты шул, шуңа нинди матур булып үскәнсең. Ә мин...

— Әниебез икебезне дә бертөсле яратты! — диде Бөдеркәй.

— Аннан соң мин чирләшкәрәк тә идем, — дип, сүзне икенчегә борырга тырышты Киребеткән. — Шуңа да мантымадым.

— Миннән бераз читкәрәк китеп утырсаң, үсеп китә аласың әле син... Читкәрәк кит, — диде аны кызганган Бөдеркәй. — Югыйсә минем тамырларны имгәтәсең...

Киребеткән әнкәсенең кочагын бик сагынган иде. Читкәрәк күченим дип кузгалмакчы булды, Бөдеркәйнең соңгы сүзләреннән уйга калды. Үзе юньләп үсмәсә үсмәс, әмма Бөдеркәйгә Әнкә өянке кочагында гына иркәләнеп үсәргә ирек бирмәс!

— Бик күчәр идем дә, китеп булмый шул... Җиле дә әллә кая китте, ул булса, ансат кына китереп ташлаган кебек, читкәрәк тә ала алыр иде, әлбәттә... Кыен булса да сыенмыймчы үзеңә... Җай чыккач күчеп утырырмын...

— Ярар алайса, — диде Бөдеркәй аны кызганып. — Күңел киң булса, икебезгә дә урын җитәр... Мин дә тамырымны кузгатып ала алмыйм шул. Алай да әкренләп-әкренләп читкәрәк күчерә-күчерә сиңа урын бирермен...

— Рәхмәт инде, — диде Киребеткән. — Ныгып китсәм, яхшылыгыңны онытмам...

Киребеткән Бөдеркәй үсеп утырган җиргә та-

мырлары белән беректе. Читкәрәк кузгалырга һич кенә дә нияте юк иде, шунлыктан, Бөдеркәйнең тамырын җәрәхәтли-җәрәхәтли тирәнрәк кереп калырга тырышты. Бер яктан, туганының киң күңеллелегенә сөенсә, икенче яктан, күргән михнәтләрен аңа сылтап үч алу турында исеннән чыгармады. Әгәр Бөдеркәй үз янына сыендырмаса, үзәнлектә корыган ботак-санаклар белән бергә үзен дә янган учакка ыргытулары ихтималын да онытты. Хәзер аның бер генә максаты — ничек тә шушында тамырланып калырга, ничек тә үсәргә! Бөдеркәйдән биегрәк булып үсәргә!

Миңа гына түгел, Киребеткәнгә дә кыендыр дип, Бөдеркәй түзде, авыр сүз әйтмәде. Киребеткәнгә урын бушатырга, тамырын читкәрәк кучерергә тырышты. Әмма тегесе шулхәтле кире иде ки, Бөдеркәй тамырын читкәрәк алган саен, иркен урын булуга сөенәсе урында, һаман да шул бичара тамырга ябышты.

Бөдеркәй, ниһаять, түземе бетеп, Киребеткәнгә ялына башлады:

— Киребеткән, син ясаган җәрәхәттән икебезгә тиешле дым оча да парга гына әйләнә, — диде.

— Бик тырышсам да, читкә китеп булмый шул, — дип ялганлады Киребеткән. — Яхшылыгыңны күпсенәсеңне белсәм, якын да килмәгән булыр идем үзеңә.

Бөдеркәйгә оят булып китте. Ул бүтән таллар ишетмәсен дип, тирә-ягына каранды — әмма һәркемнең үз эше иде, алар Киребеткән белән Бөдеркәйнең бәхәсен ишетмәделәр дә. Әнә бала таллар тырыша-тырыша көн яктысында кояшка бөреләрен ачалар, әнә үсмер таллар үзләренең алкаларын кояш нурында ялтыратып калырга ашы-

галар, әнкә таллар да алкаларына асылынган орлыкларын җилгә таратып, яшь үсентеләр хәстәрләү белән мәшгуль, ә арадагы иң мәһабәт Әнкә өянке барысына да изге фатиха биргән сыман яфракларын лепер-лепер китерә... Һәммәсе дә кояш нурына манчылып, Әнкә өянкедән фатиха алырга ашыга...

Бөдеркәй Киребеткән белән тарткалашуның мәгънәсе юклыгын аңлап алды. Аның да бит Кояш барында бөдеркәләнеп калган алкаларын нурга манчып аласы бар! Быел бит беренче тапкыр алкаларына орлыклар яшеренгән!

Бөдеркәй бер Кояшка — югарыга, бер аска — йолкыш тал ботагына карап алды да үзенең бар булган үпкәсен шунда ук онытты. Көчлеләр үзләреннән хәлсезләр белән бил алышмыйлар. Һәм парга әйләнәсе дымны Киребеткәнгә бирәсе, үзенең кирелеге белән теләсә кайда типкедә йөргән, шулай да һаман акылга утырмаган тал үсентесенә ярдәм итәсе килде аның. Бөдеркәй дә булышмаса, ул бөтенләй харап булачак! Бер әнкә балалары бит алар!

— Юкка тырышасың, — диде Бөдеркәйнең ниятен аңлап алган Песнәк. — Мин Киребеткәнне күптән беләм! Менә күр дә тор, Әнкә өянке янындагы урынны бөтенләй үзенеке итәр өчен тамырларыңны да корытыр! Юньле агач әллә кайчан үз урынын таба, ә ул һаман да күбәләк кебек очыпкунып йөрүен белде, аның кебекләр инде әллә кайчан бөдрәләнеп, орлыкларын җилгә очырдылар, ә ул барыбер акылга кермәде!

— Акылга килергә исәбендә дә юк! — диде узышлый аларның сөйләшүен ишеткән Кыр куяны. — Мин аңа үз оямда урын биргән идем. Өянке

булып киткәч, балаларыма кышка оя ясарга урын булыр, дип сөенгән идем. Ә ул тамырларын җибәреп минем оямны җимерде!

— Анда минем дә йортым, келәтләрем бар иде, — дип сүзгә кушылды Сукыр тычкан. — Әйтеп-әйтеп тә тыңламагач, тамырларын кырт-кырт иттем дә кисеп ташладым! Әнә, күрәсеңме, синең дә тамырларыңдагы дым болыт кебек күтәрелеп ята! Телисеңме, тамырыңа береккән ботакны кылыч тешләрем белән тураклап атам!

— Кыйналганны кыйнавы җиңел аны, — диде Бөдеркәй. — Сез аңарга берегез дә булышмагансыз икән. Куагансыз, һәлакәткә этәрә генә баргансыз.

Бу бәхәсне Киребеткән дә ишетеп-күреп торды. Бөдеркәй аларны тыңлап, берәр хәрәкәт ясый калса, тагын да ныграк кадалмакчы булып, тамырына беректе. Кемгәдер этлек эшләү аның кәсебенә әйләнгән иде шул, Бөдеркәйне интектерсә генә күңеле булыр, шулай иткәндә генә ул үсәр!

— Үсәр? — дип көлде аның уйларын белеп алган Сукыр тычкан. — Соң синең болай яшәвеңнең кемгә хаҗәте бар? Бөдеркәй риза булса, мин синең черек тамырларыңны әллә кайчан кимереп ташлар идем!

— Тия күрмә! — дип туктатты аны Бөдеркәй. — Син минем җәрәхәтле тамырымны кисеп ташла да дым чыкмасын өчен киселгән урынны сылап куй. Ә мин аның урынына яңа тамыр җибәрермен.

— Урын икегезгә дә җитми бит, — дип каршы төште Сукыр тычкан.

— Күңел киң булса, сыярбыз. Кояш барыбызга да бер елмая.

Сукыр тычкан башын кашып, уйланып торды да, Бөдеркәй кушканча эшләргә булды. Ул җәрәхәтле тамырын кимереп, Киребеткәнгә юл ачып кына калмады, ә Бөдеркәйнең әлеге тамырындагы дым юлын ямап, нык итеп ябып та куйды. Бөдеркәй авыртуны бөтенләй сизмәде — чөнки аның бүтән тамырлары үзләренә тиешле дымны җир астындагы чыганактан җитәрлек алалар иде инде.

— Бик зур рәхмәт сиңа, Сукыр тычкан, — диде Бөдеркәй. — Телисең икән, минем тамырларым янында оя яса.

— Минем оям синең тамырларыңнан ерак түгел, кем белә, бәлки киләчәктә кирәге дә чыгар, анысын белеп булмый, — диде моңа каршы Сукыр тычкан. — Әмма Киребеткән зыян салырга уйласа, кара аны, сак булсын!

— Зыян китереп карасын! — диде Сары песнәк. — Бөтен яфракларын чүпләп бетерермен!

— Кәүсәсен кимерермен! — диде Куян.

— Бик зур рәхмәт сезгә, дусларым, — диде Бөдеркәй. — Тик кирәге булыр микән? Без бит Киребеткән белән туганнар, менә күрерсез, ничек тату булып үсәрбез, әйеме, Киребеткән?

Киребеткән үзенең баштагы уйларыннан беренче тапкыр уңайсызлану хисе кичерде, кәүсәсе кызыша башлады, шунлыктан ни дип җавап бирергә дә белмичә, башын гына чайкады. Бу аның яңа тернәкләнеп килгән тамырларыннан тереклек дымының өскә таба күтәрелүе иде. Дым бернинди тоткарлыксыз күтәрелде дә, ботакларда нәни бөреләр барлыкка килде. Әмма әлегә Киребеткән моны сизмәде. Ул бер яктан, үзенең моңарчы гел әшәкелек кенә эшләргә тырышуын һәм шуның ар-

касында һәлак була язуын, уңдырышлы туфракка, мәрхәмәтле туганы янына эләккәч, күңелендәге кирелекнең, явызлыкның болыт кебек тарала баруын да аңламый иде әле. Әмма ул әле шикләнеп, әле ачуланып караган Бөдеркәйгә дә, үзен сүккән Сары песнәккә дә, Куянга да, Сукыр тычканга да үпкәли алмады, чөнки аларның хаклы икәнлеген аңлады.

Ә үзе кирелеге аркасында күргән газапларының берьюлы дым белән таралып китүен, гәүдәсенең тураеп, өскә күтәрелгәнен сизде. Кинәт өермә кузгалып алды, яшенле яңгыр явып үтте. Киребеткән куркып шәлперәйде, әмма ни хикмәт, бу өермә дә, коеп үткән яңгыр да аны урыныннан кузгата алмады. Киресенчә, өермә узып, шактый вакыт үткәч, кояш нурына җылынудан күтәрелеп караса, үзен Бөдеркәйнең кочагында күреп, гаҗәпләнде. Ул аны үзенең ябалдашлары белән каплап торган икән. Аннан соң гына үзенең ботакларының да Бөдеркәйнеке кебек сары алкаларга күмелүен, бөдрә талга әйләнүен, еректан караганда кояштай балкып күренгәнен аңлап, куанычыннан нишләргә дә белмәде.

Тирә-яктагы таллар лепер-лепер килеп сөйләшәләр иде:

— Карагыз әле, яшенле яңгыр безгә тагын бер Бөдрә тал алып килгән!

Киребеткәнгә моны ишетү чиксез рәхәт иде. Аның мактанып:

— Типкедә йөргән Киребеткән бит мин! — дип кычкырасы килде, әмма вакытында аңына килеп, тыелды. Һәм ул үзен кочагына сыендырган Бөдеркәйгә кысан булмасын дип, читкәрәк кузгалырга теләде.

Бөдеркәй елмайды.

— Без бит синең белән бертуганнар, — диде. — Бер-беребезгә таянышып үссәк кенә, җил-давыллардан да курыкмабыз. Күрәсеңме, синең кебек матур өянке якын-тирәдә юк. Әнкә өянке дә үзеңә ничек соклана. Кирәк чагында ул безне, кирәк чагында без аны җил-давылдан ышыкларбыз.

— Мин Әнкә өянкедән дә биегрәк үсәрмен, барыгызны да ышыкларммын, — диде Киребеткән.

— Вакыты җиткәч, үзең дә минем кебек булырсың, — дип елмайды Әнкә өянке. — Алкаларыңа орлыклар кунар, алар җилгә очып ерак-еракларга таралырлар, үз урманың булыр. Минем балаларым сез генә түгел, ерак-еракларда да күп алар. Хәзер я Җил, я Яңгыр миңа бер-бер баламның хәбәрен алып килә — әнә, күрәсезме, аланлыкта җыелган кошлар төркемен? Орлыклар чүпли алар. Ерактагы Өянке кызымның орлыкларын...

— Кошлар орлыкларны чүпләп бетерерләр бит, — диде Киребеткән.

— Тиешлесен яңгыр җиргә күмде инде аларның. Ә җир өстендәгесе кошларга күчтәнәч, — дип аңлатты Әнкә өянке. — Синең дә озакламый шулай үз орлыкларың җиргә төшеп, урман үстерергә дә, күчтәнәчкә таратырга да җитәрлек булыр.

— И-и, аңа хәтле әле, — дип, оялчан гына көлде Киребеткән. Аңа бик рәхәт иде. Ул тиздән үзенең орлыклар чәчүен, ул орлыклардан урман үсүен күз алдына китерде. — Кая әле?! Мин Киребеткәннән булыр микән, ә?

— Кирелегең Яңгыр, Җил белән очып бетте инде. Ә алкаларыңдагы орлыкларың исәпсез-хисапсыз булыр — кара әле, бер генә яфрагың да күренми үзеңнең, алкалар да алкалар гына!

Тагын Яңгыр явып, Җил исте. Бу юлы инде Җил күптән түгел генә Киребеткән, хәзер исә Бөдрә тал булып үсеп җиткән агачның алкаларындагы орлыкларын якындагы буш аланга тарата иде.

АЛТЫНКАЙ

Кояш нурлары бөтен кышны әниләре белән зиннәтле сарайда үткәрделәр. Әниләре балаларын калдырып, беразга гына күкне әйләнеп чыга иде дә кире сараена әйләнеп кайта иде.

Менә яз җитте. Кояш елмайды һәм кыш буена биктә яшәгән нурларын ирекккә чыгарды. Дөнья нурга күмелде. Тәрәзәләрне каплап торган пәрдәләр тартылды, шуны гына көткәндәй, кояш нурлары өй эчләренә көлтә-көлтә булып сибелделәр, ирекккә чыгу куанычыннан бер-берсен узышып сикерештеләр дә төрлесе төрле якларга таралыштылар. Чөнки аларның һәркайсының үз эше, үз вазифасы бар — кайберсе умырзаяларны уятырга, кайберсе кар катламын эретергә, ә кайберәүләре чишмә суларына тәм кертергә ашыктылар. Бары тик иң кечкенә Алтынкай гына ни эшләргә кирәген белми, абыйлары артыннан калмыйм дип ашыгып, әнисенең нәрсә әйткәнен ишетмичә калган иде. Алтынкайның дөньяга беренче тапкыр гына чыгуы әле, әнисенең иң төпчек, иң бәләкәй нуры бит ул.

Кич җитте. Кояш үзенең балалары кайтыр вакыт җиткәч, сарай ишекләрен киң итеп ачып куйды да ял итәргә ятты. Чөнки ул бик арыган иде. Бүген кыш буена йокымсырап яткан табигатькә

җан өрде: үлән бөртекләрен сыйпады, аларның һәркайсына чык элде, шул чык тамчылары белән кошларны коендырды, агачларның бөреләрен уятты.

Кич җиткәч кояш нурлары сарайларына йокларга кайттылар, тик Алтынкай гына күренмәде.

Нурларның элек тә кайтмый калу очраклары була иде, шунлыктан моңа берсе дә аптырамады.

Нурлар икенче көнне тагын таң белән үк дөньяны яшәртергә тотындылар. Аннан соң, вакыт җиткәч, тагын кайттылар. Өченче көн дә, дүртенче көн дә шулай дәвам итте, атна үтте, әмма Алтынкай кайтмады.

Алтынкайның болай озак вакыт кайтмыйча торуы гадәти хәл түгел иде. Кояш нурларына моңа хәтле берни дә киртә була алмаса да, нихәтле вакыт үтте бит...

Кояшка үз күген ташлап китү мөмкин булмаганлыктан, аның исәпсез-хисапсыз нурлары көн саен җир өстенә сәяхәткә чыктылар һәм бөтен җирне капшап, Алтынкайны эзләделәр. Юк иде, шаярып үлән арасына да яшеренмәгән, чардакка да менеп кунакламаган, бүрәнә ярыкларына да кереп качмаган. Көндезләрен исәпсез-хисапсыз нурлар арасында нәни Алтынкай югалып та калсын, ди, тик төннәрен нәни генә ут та караңгылыкны ерып әллә кайларга кадәр күренә бит.

Нурлар җир өстендә төрле утларны күрделәр. Әнә кайдадыр аучы учак яга, әнә кемнеңдер саксызлыгы аркасында йортка ут капкан, әнә кайдадыр озын торбадан чыккан ялкын күккә сикерә, исәпсез-хисапсыз электр утлары караңгылыкны ерып, әллә кайларга хәтле яктырта. Әмма Алтынкай алар арасында да юк иде.

Кояш үзенә ярдәмгә Айны чакырды. Ләкин Ай да:

— Мин бөтен җирне керфек тә какмыйча күзәттем. Алтынкайны күрмәдем, — диде.

Шуннан соң Кояш йолдызлардан сорады:

— Күрмәдегезме минем Алтынкаемны? — диде.

— Күрмәдек, — диделәр йолдызлар да.

Алар да төн буена җир өстен күзәткәннәр, тик Алтынкайны күрмәгәннәр.

Кояш кайгыга батты, йөзен болытлар каплады. Аның күзеннән аккан яшьләр җир йөзенә эре-эре тамчылар булып тамдылар. Коеп яңгыр ява башлады.

Җир йөзендә өч төн, өч көн буена гарасат купты. Күптән түгел генә яфрак ярып, чәчәккә бөреләнгән агачлар, үләннәр су астында калды. Йортларны су басты, тирә-як тоташ су эчендә калды.

Кояш елап туйгач, Алтынкай күренмиме дип, җир йөзенә күз салды һәм коточкыч хәл күрде. Кешелергә дә, барлык җан ияләренә дә беркая кереп котылыр урын калмаган иде. Шунда гына Кояш бер Алтынкай аркасында җир йөзенә күпме хәсрәт китергәнен аңлап алды. Юк, болай ярамый, болай булса, Җир үзе дә, кешеләре дә, хәтта исән булса, Алтынкай үзе дә һәлак булачак бит!

Кояш керфегенә эленеп калган яшьләрен селкеп төшерде дә елмайды. Бу яшьләр җир өстенә кояшлы яңгыр булып тамдылар. Күктә салават күпере балкыды, елгалар үз урыннарына кайттылар, кешеләр түбәләрдән, агачлардан, тау башларыннан төштеләр, җирдә гадәти тормыш башланды.

Ә Алтынкай бу вакытта әнисенең дә, туганна-

рының кайгысы турында уйламый, ул көн белән төннең аермасын да, ничә тәүлек үткәнен дә белми иде. Кояш сарайда туганнарының җылы кочагында яшәп, дөньяга беренче тапкыр гына чыкканлыктан, аңа җирдәге бөтен нәрсә дә яңа, кызык, күңелле иде. Ул агачтан агачка сикереп уйнады, кар астыннан баш төрткән умырзаяларны сыйпап үтте, кояш нурына уянып чыккан күбәләкләр белән шаярды. Ул үзе дә әнә шул күбәләкләр кебек тоттырмас һәм тиктормас иде шул.

Туйганчы уйнар, сикерер иде дә кире сараена кайтыр иде. Ул кичкә таба, ял итмәкче булып, тау башындагы бер түмгәк төбенә кунаклады. Шулчагында аның колагына кемнеңдер авыр ыңгырашуы ишетелде һәм ул куркып бүтән урынга сикерергә әзерләнде. Әмма ыңгырашу кабатланды, — ул Алтынкай кунаклаган түмгәк астыннан килә иде.

Алтынкай колагын салып тыңлап торды.

— Кем анда? — дип сорады.

— Мин, — дип җавап бирде зәгыйфь тавыш. — Бу мин — Сандугач.

— Нигә кеше куркытып ятасың? — диде Алтынкай.

— Мин үзем куркам. Язга чыккач кына якты кояшны күрмичә үләрмен дип куркам.

— Минем янга чык, — диде Алтынкай.

— Бик чыгар идем дә, аякларым кысылган шул.

— Ник кысылды?

— Аякларым таш астында калды. Таш авыр, салкын, кузгатып булмый.

— Кайда соң син, нишләп мин сине күрмим?

— Кара еланның зинданында мин. Ул очып йөрмәсен дип, аякларымны таш белән бастырып

куйды. Еланнар сандугач сайравын яратмыйлар.

— Әз генә иртәрәк белгән булсам, туганнарыма тоткарланасымны әйткән булыр идем, аннан соң алар үзләре дә дәррәү булышырга тотынырлар иде. Ә хәзер... Мин кайтмасам, туганнарыма әләгәчәк бит! Аннан соң Кояшның аларны сарайдан чыгармавы бар. Кояш нурлары өчен биктә ятудан да зуррак җәза юк.

Мин кайтыйм да аларга әйтим. Таң белән үк сине коткарырга килербез. Аңарчы түзә аласыңмы?

— Аягымны таш басып тормаса, түзеп тә булыр иде, — диде Сандугач. — Таңга хәтле чыдый алмам шул.

Алтынкайның бөтен икеләнүләре юкка чыкты. Ул, бер ярык табып, Сандугач янына сикерде.

Караңгы, салкын зиндан гөлт итеп яктырды, тирә-якка сихәтле җылылык таралды. Алтынкай әле Сандугачны җылытты, әле аның богаудагы аякларын ычкындырырга тырышты, әмма ташның бирешергә исәбе юк иде.

Таң атты. Таң белән җир өстенә таралган кояш нурларының яктысы зинданга да кагылып үттеләр. Алтынкай үзенең кайдалыгын әйтер һәм аларны ярдәмгә дәшәр өчен чыкмакчы иде, әмма чыгарга юл тапмады.

Алтынкай ары бәрелде, бире бәрелде.

— Тырышма, барыбер чыга алмассың, — дип ысылдады Кара елан. — Сандугач минем әсирем. Хәзер син дә минем әсирем булдың. Мин сезнең икегезне бергә юк итәм.

Әнисеннән һәм туганнарыннан гел әдәплелеккә генә өйрәнгән Алтынкайга мондый тупаслык гаҗәеп сәер иде. Ул бермәлгә аптырап калды. Тик

зиһенен тиз генә җыеп өлгерде. Чөнки әнисенең: "Җир йөзендә изгелек белән явызлык янәшә йөри", — дигәне исенә төште.

Алтынкайның Сандугачка ярдәм итүе һәрхәлдә явызлык булмас, чөнки теләге изге бит аның. Ә өстәге тавыш бер дә изгелек итәргә охшамаган. Алайса, бу явызлыкның үзе буладыр әле. Ә изгелекнең явызлыкны һәрвакыт җиңгәнен ул ишетеп белә. Кояш нурларының җылысы тимичә калган бер генә җан иясе дә, бер генә яфрак та юк. Явызлыкны да изгелеккә әйләндерү кодрәтенә ия бит кояш нурлары.

Тик ул бик бәләкәй иде шул, явызлыкны изгелеккә әйләндерүдә тәҗрибәсе юк иде.

— Башта Сандугачны тотып ашыйм, аннан соң синең үзеңне йотам. Шуннан соң мин кодрәт иясенә әйләнәм. Җиһандагы бөтен җанварлар патшасы булам. Шул исәптән кешеләрнең дә, — диде Кара елан.

— Сандугачның ни гаебе бар соң? — диде Алтынкай.

— Ул миңа карендәшләрен чакырып китерүдән баш тартты.

— Нигә кирәк алар сиңа?

— Мин сандугачларны яратам! — дип ысылдады Кара елан. — Бик яратам.

— Ышанма аңарга, — диде Сандугач. — Ул, сандугачларны зинданына ябып, алардан ризык амбары ясамакчы. Ашамакчы, бөтенесен йотып бетермәкче!

— Сандугачларның ите тәмледер! — диде Кара елан. — Югыйсә шундый матур итеп сайрый алмаслар иде. Синең аркада ниятем барып чыкма-

ды. Ярар, үзең теләгән язмыш. Барыбер берәрсе риза булыр әле. Бүген син миңа азык булырсың.

— Булсам булырмын, әмма бүтән сандугачлар синең каршыңа килмәс!

— Үзең исән калыр идең! Алар моның өчен рәхмәт әйтерләр дип беләсеңме? Юк! Шулай булгач, хәзер бер генә сызгырып җибәр, алар сине коткарырга өерләре белән зинданга ташланачаклар! Шулчагында мин аларны бикләп куям. Ә сине иреккә җибәрәм.

— Миңа андый тормыш кирәкми.

— Кирәкми, имеш! Әллә мине ризык тапмас дип беләсеңме? Синең карендәшләрең килмәсә, миңа бүтән кошлар, бөҗәкләр дә җитәрлек. Сиңа алар да кызганычмы?

Алтынкай әле куркуны белми иде, җир астында да, кара төндә дә аңа барыбер. Ул Сандугачны һәм үзен бикләп торган зинданның авыр тимер ишеген кат-кат капшый башлады. Җылы нур салкын тимергә тию белән ул җылынды, аңардан тамчы-тамчы су тама башлады. Баксаң, ул бер дә тимер ишек түгел, ә кантарлы боз кисәге икән, бер заман эреп үк бетте. Эрүен эреде, әмма бу юлы Сандугач аңардан аккан су астында калды. Кояш нурлары җылыткан чык суларында гына коеныргa яраткан Сандугач дер-дер калтырап туңарга тотынды. Тик озакка түгел. Алтынкайның су өстендә бер-ике тапкыр сикергәләп алуы булды, су җылынды һәм бу урында гаҗәеп матур күл хасил булды, күл дулкынланып алды да Сандугачның аягын басып торган ташны комга әйләндерде. Сандугачның аяклары ычкындылар, күл өстендә камышлар үсеп чыкты, күбәләкләр нурга күмелеп уйнаклый-уйнаклый оча башлады-

лар. Еланның сандугачларны бикләр өчен дип төзелгән зинданында үз агачлары, үз күлләре, хәтта үз кояшына хәтле булган сокланггыч дөнья пәйда булды.

Кара елан моны сизмичә калды. Ул киребеткән Сандугачны үзенә буйсындыру өчен хәйләләр эзләргә тотынды. Әмма үзе белгән хәйләләрнең берсеннән дә файда тапмады. Аның Сандугачны хәзер үк тотып йотасы килми иде, чөнки бүтән сандугачларның үзен болай гына калдырмасыларын белә иде. Тоткын сандугач аларның иң иркә, сөйкемле сеңелләре бит. Ә менә аларның барысын да бергә зинданга ябып куя алса, Кара еланны берни эшләтә алмаслар.

— Ә кем белә аның кайда юкка чыкканын? — дип уйлады Елан. — Ятсын зинданда. Аны кабып йотарга беркайчан да соң түгел.

Ул Сандугачның ни эшләгәнен белергә теләп, җиргә колагын куеп тыңлый башлады. Аннан ыңгырашкан, ялварган авазлар ишетмәгәч, игътибар беләнрәк тыңларга тотынды. Күптән түгел генә салкын, караңгы зинданнан кошларның черкелдәве, күбәләкләрнең лепер-лепер итеп канат җилпүе ишетелә. Ул ишекне ачып карыйм дип иелгән генә иде, аннан бөркелгән яктылыктан күзләре чагылып, чак кына аска егылып төшмәде. Елан тиз генә читкә шуышты да түмгәк астына посты. Зәһәрләнә дә алмады, аңа бик тә моңсу, күңелсез булып китте.

Тукта әле, анда бер генә түгел, әллә нихәтле сандугач җырлый түгелме соң? Кайда ишеткәне бар соң бу җырны? Таныш та, таныш та түгел бу җырны ишеткәне бар иде аның. Әйе, бар иде! Еланнар патшалыгындамы? Еланнар арасында

мондый моң булмас. Анда бары тик зәһәр ысылдау гына.

Әле яңа барлыкка килгән кояшлы дөньяда җыр яңгырый, моң тарала. Сандугачлар бер моңлана, бер куана.

— Моңланыгыз, моңланыгыз! — дип ысылдады Кара елан. — Минем җыр сөймәвемне белеп үртәвегезме бу? Мин хәзер бу дөньяны еланнар сазлыгына әйләндерәм! Юк, берегезне дә ашамыйм, ә Еланга гына әйләндерәм!

Кинәт Кара еланның исенә төште — ул бит кайчандыр үзе дә сандугач иде! Җир өстендә шуышып, зәһәрләнеп яшәүче Елан түгел, ә зәңгәр күктә канат кагынып оча торган җырчы кош иде! Сайравына кешеләр генә түгел, сандугачлар үзләре дә таң калалар, әнкә сандугачлар бала сандугачларга аныңча сайрарга өйрәтәләр иде.

Сандугач үзенең матур җырлавы белән масайды, тора-бара үзеннән матуррак сайрый башлауларыннан куркып, бала кошларны моңсыз җырларга өйрәтә башлады. Матур сайраучы кошлар картаеп үлделәр, моңсыз сандугачлар исә күбәйделәр. Сандугачларның җырлавын таң калып тыңларга яраткан кара каргалар, ала каргалар, саесканнарга хәтле аларның тавышыннан туеп, дәррәү һавага күтәрелә башладылар.

Тора-бара бу якларда моңсыз сандугачлардан бөтен кошлар — песнәкләр дә, чыпчыклар да, кызылтүшләр дә, сыерчыклар да, ала каргалар, кара каргалар, хәтта тилгәннәр дә туеп, качып беттеләр. Кошлар юкка чыккач, алар яратып чүпли торган бөҗәкләр үрчеделәр, үрчеп кенә калмадылар, ә үләннәрне, чәчәкләрне, яфракларны, хәтта агачларның бөтен кәүсәләренә хәтле кимерә

башладылар. Җир йөзен нурландырып торган яшеллек юкка чыкты, аның каравы, симез эре бөҗәкләр, кортлар мыжгып тора башлады.

Матур җырлаучы Сандугач үзе дә тора-бара моңын онытты.

Сандугачлар чын-чынлап кайгыга төште. Алар моңнары югалганны аңладылар. Ә моңсыз булгач, сандугач сандугач булмый бит инде, яши алмыйлар сандугачлар моңсыз. Ашыгыч рәвештә киңәшмә җыйдылар һәм җепнең очы үзләрен моңсыз җырларга өйрәтүче Сандугачка килеп терәлде. Сандугачлар аңа нинди җәза бирү турында уйлана башладылар. Ә җырчы Сандугач үзе дә алардан битәр кайгыга төшкән иде. Ул элеккечә җырлап карамакчы булып авызын ачкан иде дә, үз тавышыннан үзе үк куркып бер чокырга төшеп качты һәм Кара еланга әверелде.

Әкренләп яңа сандугачлар туа торды. Алар үзләренең табигый моңнары, җырлары белән дөньяга килделәр. Бүтән бер генә сандугач та бала сандугачларны җырларга өйрәтүне үз өстенә алмады. Сандугач—табигать баласы, ул моңны да табигатьнең үзеннән—яфраклар лепердәвеннән, таң чыкларыннан, төнге ай нурыннан, шәфәкъ яктысыннан ала, шулай булып калсын да, диделәр.

Әкренләп бу якларның элекке яме, элекке моңы, җырлары кире әйләнеп кайтты. Кара елан озак вакытлар сазлыкларда, чокырларда яшәде, ул үзенең үткәнен бөтенләй хәтереннән чыгарды. Хәтта еланнар да аны үз яннарыннан кудылар, ул бөтен гомерен ялгызлыкта үткәрергә дучар ителде.

Ә менә бүген үзе казыган зиндандагы якты

дөньядан килгән моң аңа барысын да искә төшерде. Һәм ул моңга кушылып сызгырына, ысылдый башлады. Нияте изге иде югыйсә, сайрап кына карамакчы иде, тик үз тавышыннан үзе куркып, бәргәләнә-бәргәләнә елый башлады. Аның кабаттан сандугач буласы, канат кагып зәңгәр күккә күтәреләсе, бүтән сандугачлар белән бергәләп таң алдыннан талларга кунып сайрыйсы, кояш нурларында коенасы килде.

— Мин элек нинди бәхетле булганмын! Миңа мондый бәхет бүтән беркайчан да булмас инде. Мин аның кадерен белмәгәнмен, — дип елады ул.

Моны күреп Алтынкай аны бик тә кызганды һәм аның күңелен әз генә булса да күрү өчен әле аска, әле өскә сикереп уйный башлады. Тик елан моны күрмәде. Күрергә — аның күзләре яшь белән тулы иде шул.

Шуннан соң Алтынкай аңа эндәште:

— Телисеңме, мин сине дә үзем кебек сикерергә өйрәтәм?

— Мин сикерә белмим шул, — диде Елан.

Алтынкай аны тыңлап тормады, аркасына ук менде дә үрле-кырлы сикерергә тотынды. Ул сикергән саен Еланның кытыгы килде һәм кытыклануга түзә алмыйча үзе дә үрле-кырлы килеп көлә-көлә сикерергә кереште. Алтынкай исә аның яныннан һавага сикерде, Елан аның артыннан, шулай онытылып сикерә торгач, бер заман караса — ни күрсен — ул кабат җырчы Сандугачка әйләнгән иде!

Билгеле, моңа Алтынкай да сөенде. Сөененченнән үзе дә кояшка әйләнде.

— Рәхмәт сиңа, Алтынкай! — диде Сандугач. —

Син мине кузгатып зәңгәр күккә алып мендең, Сандугачка әйләндердең.

— Синең үзеңә дә рәхмәт, — диде Алтынкай. — Мин дә бит синең аркада кояшка әверелдем.

Шуннан соң Сандугач талга кунып сайрап җибәргән һәм кечкенә генә нурдан якты кояшка әйләнгән Алтынкай турында дөньяга җыр таратткан, ди.

АК РОМАШКА

Зәңгәр болында, зәңгәр чәчәкләр арасында Ак ромашка үсте. Гадәти болын, гадәти чәчәкләр арасында булса, бу вакыйганы белүче дә, күрүче дә булмас иде. Әмма болын зәңгәр иде шул, аңарда үскән чәчәкләр дә, чәчәкләр арасында очкан күбәләкләр дә зәп-зәңгәр иделәр. Хәтта бу болынның зәңгәрлегенә гаҗәпләнеп очып кергән кошлар да зәңгәрләнә иде, шунлыктан зәңгәр чәчәкләр арасыннан кыяр-кыймас кына үрелеп караган нәфис Ак ромашканы күреп барысы да сокландылар.

— Карагыз әле, нинди матур ромашка! — диделәр.

— Матурын матур да, тик монда аклыгын озак саклый алырмы? Зәңгәрлек аклыкны капламасмы? — диде иң акыллы, дөньяны бүтәннәргә караганда күбрәк белгән чәчәкләрнең берсе.

Аның бу сүзләрен ишеткәч, бүтән чәчәкләр уйга калдылар һәм ак чәчәккә үсәргә комачауламас өчен ара калдырып, як-якка авыштылар.

Ак ромашка тирә-якның иркенәюен сизеп, таҗларын иркенләп ачты һәм рәхәтләнеп үсә башлады. Аның аклыгының саклануын күреп, бүтән

чәчәкләр куандылар, кошлар матурлыгын мактап җырлар чыгардылар, җилләр иркәләп сыйпадылар, яңгырлар аның тамырларына шифалы дым бирделәр.

Әмма якында гына үсеп утырган Тигәнәкнең моңа эче пошты.

— Харап икән, моңарчы Ак ромашка күргәннәре юк иде, диярсең. Минем яфракларым зуррак та, энәләрем чәнечкелерәк тә, бер җирем дә аңардан ким түгел, хәтта артыграк та әле, — диде ул.

Зәңгәр болында, зәңгәр чәчәкләр арасында аклыгын җуймыйча үсеп утырган Ак ромашка турындагы хәбәр тирә-якларга таралды. Бу хәбәрне ишеткәч, ак чәчәкне күрер өчен ерак-ераклардан сайрар кошлар килде. Алар да Ромашканы күреп таң калдылар һәм моңа хәтле зәңгәр болын турында гына җырлаучы кошлар шушы болын уртасындагы Ак ромашканың матурлыгы турында да җырлар чыгардылар. Әмма берсе дә бөтен болынны каплап үсәргә тырышкан Тигәнәкне телгә алмады. Әйтерсең шушы өф итсәң егылырга торган Ромашкадан башка берни күрмиләр иде.

Тигәнәк чәнечкеләрен кабартты. Тирә-яктан очып килгән кошларны, күбәләкләрне чәнчеп куркытырга теләде. Әмма аның нияте барып чыкмады. Кошлар аңа игътибар итмәделәр. Аның тырпайган тигәнәкләренә басып, чәчәкне мактадылар. Кайбер кошлар исә, Тигәнәккә кунып ял иттеләр. Ә бер сандугач Ромашкага шулхәтле гашыйк булды, Тигәнәккә оя корып, шунда яшәп үк калды. Ак ромашкадан башканы күрмәгән Сандугачка Тигәнәкнең ачуы чыкты.

— Бу нинди ваемсызлык? — дип ыжылдады

ул. — Оясы миндә, ә күзе синдә? Кайда монда дөреслек?

Ак ромашка оялып башын аска иде. Анынча, Тигәнәкнең сүзләрендә хаклык бар иде. Тигәнәк нинди баһадир гәүдәле, бүрек сыман кабарып торган чәнечкеләре үзе генә дә ни тора! Аны беркем дә кыерсыта алмый, Ромашка кебек өф итсәләр дә сыгылырга тормый, ә давылларга да исе китмичә утыра бирә!

Әмма Ак чәчәк моны беркемгә дә аңлата алмый, чөнки һәркем үз җыры белән мәшгуль, Ромашканың аклыгы аларның күңелен әсир итеп алган иде.

Әнә шулай итеп, җәй буенча зәңгәр болын уртасында Тигәнәк белән Ромашка бергә яшәделәр. Ромашка матурланды, Тигәнәк зәһәрләнде.

Бичара Тигәнәк! Җырлар тууга матурлык, батырлык сәбәп булуын, ә зәһәрлекнең нәфрәт кенә уятуын каян аңласын соң ул?

Җылы яңгырлары белән ямьле җәй үтеп китте. Зәңгәр чәчәкләр салкын кышларга әзерләнеп, җиргә яттылар. Алар инде киләсе җәй өчен орлыклар җиткереп, җиргә сибәргә һәм аны яфраклары белән капларга өлгергәннәр иде. Әмма Ак ромашка гына орлык җиткерә алмады, чөнки Тигәнәкнең киң яфраклары аңарга төшәсе кояш нурларын каплап бетергәннәр иде.

Ак ромашканың матурлыгы турында сайраучы кошлар да җылы якларга очып киттеләр.

Ниһаять, болын уртасында алар икәү генә басып калдылар — киң күкрәкле Тигәнәк һәм нәфис Ак ромашка. Ромашка көзге ачы җилләрдән дерелдәп Тигәнәккә сыенды.

Тигәнәк хәзер тантана итә иде. Чөнки киләсе

елда ул зәңгәр болынның патшасы булып үзе калачак, аның турында кошлар җыр чыгарыр, ә Ак ромашка булмас, киләсе җәй өчен орлыклар җиткерә алмады бит.

Беркөнне болын уртасыннан зәңгәр күзле кыз бала йөгереп үтте. Сулган болынга зәңгәрлек кире кайтты диярсең—тирә-як шат көлү авазлары белән тулды. Балкып кояш чыкты. Ә Тигәнәкнең моңарга ачуы чыкты. Болай булгач, Ромашка башын күтәреп, кояштан хәл алачак, җитми калган орлыклары тулачак һәм киләсе яз болында бер генә түгел, әллә ничаклы ромашкалар булачак һәм Тигәнәкнең матур хыяллары чәлпәрәмә киләчәк иде.

Тигәнәк кызчыкны эләктереп алды да аның тәненә чәнечкеләрен батырды.

Кызый ачыргаланып кычкырып җибәрде. Аның тавышын ерак та түгел уйнап йөргән маэмай ишетеп алды да кызга ярдәмгә ташланды. Тигәнәк аны да чәнчеп-чәнчеп алды.

Хәзер, кызыйга ияреп, маэмай да шыңшый иде.

Аларның тавышын ерак түгел урман авызында кипкән ботак җыеп йөрүче бабалары ишетте. Ул балтасын иңенә салып килгәч, эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлап алды. Тигәнәкне төбе-тамыры белән алып ташлар өчен балтасын күтәрде. Ромашка күршесенә төшәсе балтаны күреп, калтыранырга тотынды.

— Тимәгез аңа,—дип, чәнечкеләргә кадала-кадала бар көчен җыеп, башын күтәрде һәм ялварып бабайга текәлде.

Карт, Тигәнәккә уралып үскән Ромашканы күреп, балтасын төшерде.

— Ай-яй!—диде ул онытына.—Менә ни өчен

сезне үзенә якын җибәрмәскә тырышкан ул! Зәңгәр болында зәңгәр чәчәкләр генә үсә дип уйлаган идем. Ак ромашканы өзәрсең дип курыккан икән ул!

Кызчык елаудан, маэмай өрүдән туктады. Алар Тигәнәккә гаҗәпләнеп, сокланып карадылар. Кызый Тигәнәкнең батырлыгы турында шул минутта ук җыр чыгарды. Ул җырны алар өстеннән җылы якка очып баручы кошлар канатларына элеп алдылар да еракларга тараттылар.

Тигәнәк бу җырга сөенде дисезме? Юк, ул бик тә оялды. Оялуыннан кып-кызыл булды.

Үткән-барган кешеләр бер-берсенә уралып үскән Тигәнәк белән Ромашканы күреп:

— Карагыз әле, нинди матур чәчәкләр, — дип гаҗәпләнделәр.

Тигәнәк розага әйләнгән иде.

Сезнең зәңгәр чәчәкләр арасында гына түгел, бөтен тирә-якта сибелеп үскән кечкенә кояшны хәтерләткән ак таҗлы чәчәкләрне күргәнегез бардыр. Явыз Тигәнәкнең күз явын алырлык роза чәчәгенә әверелүенә сәбәпче булган Ромашканың орлыгыннан үскән чәчәкләр шулар үзләре була инде.

КЕРПЕ НИГӘ КУРЫКМЫЙ?

Яшәгән, ди, бер Төлке. Матур да, ягымлы да, хәйләкәр дә булган. Әмма бик каты куркак икән. Ул үзенең куркаклыгыннан туйган һәм батырлык юллап киткән.

Бара торгач, Арысланны күргән.

— Арыслан абый, Арыслан абый, үзеңдәге ба-



тырлыкның беразын гына миңа бирмәссеңме? — дигән.

— Бик бирер идем дә, тик миндә артык батырлык юк шул, — дигән Арыслан.

Төлке ары киткән. Филне күргән.

— Фил абыкаем, — дигән ул. — Үзеңдәге батырлыкның беразын гына миңа биреп тормассыңмы?

— Бик бирер идем дә, — дигән Фил, — батырлык үземә дә юк әле. Әгәр дә булса менә шушы бәләкәй генә тычканнан куркыр идеммени? — Һәм үзенең борынын күтәреп күрсәткән.

Шунда гына Төлке Фил борынында утырган Тычканны күргән.

— Тычкан, Тычкан абзыкай, — дигән ул, — үзеңдәге батырлыкның беразын гына миңа бирмәссеңме?

— Бик бирер идем дә, — дигән Тычкан, — үземә дә юк шул. Әгәр дә булса, Песидән качып Фил борынында утырыр идеммени?

Шунда Төлке Тычканның Фил борыныннан төшүен сагалап яткан Песине күргән.

— Песикәй, Песикәй, — дигән ул. — Үзеңдәге батырлыкның беразын миңа бирмәссеңме?

— Бик бирер идем дә, — дигән Песи, — тик Фил борынына менеп Тычкан тотарга батырлыгым җитмәгәч, сиңа каян алыйм икән?

Шуннан соң Төлке ары киткән. Каршына Аю очраган. Аягы авыртуына чыдый алмыйча үкереп-үкереп елый икән.

— Аю абзыкай, — дигән Төлке, — үзеңдәге батырлыкны миңа да бирче?

— Бик бирер идем дә, — дигән Аю, — менә шушы бәләкәй генә йомгактан курыккач, каян алыйм икән сиңа бирергә батырлык?

Төлке йомгакка эндәшкән. Йомгак дигәне Керпе икән.

— Бик бирер идем дә, — дигән Керпе, — кирәк чагында үзең миңа булышырсыңмы соң?

Төлке риза булган. Керпе аңа энәләренең беразын биргән. Шуннан соң Төлке берәүдән дә курыкмыйча яши башлаган.

Аңардан күреп Арыслан да Керпедән батырлык энәләрен алып, тунына кадаган. Аңардан күреп Песи, аннан соң Тычкан, Тычканнан күреп Фил Керпедән батырлык сораган. Керпе берсенә дә каршы килмәгән, әмма барысына да Төлкегә куйган шартын әйткән.

Әкренләп Керпенең энәләре урмандагы барлык җанварларга күчеп беткән, тора-бара үзенә берәү дә калмаган.

Салкын кыш җиткән. Энәле туны булмагач, Керпе туңа башлаган. Ул җылыныр өчен Арыслан янына киткән.

— Арыслан абый, — дигән, — мине бераз гына җылытмассыңмы?

Арыслан аны күрмәмешкә салышкан.

Аннан соң ул Песигә, Тычканга, Филгә киткән. Тегеләре дә аны танымамышка салышканнар.

Керпе энәләрен биргән бөтен җанварларны йөреп чыккан, әмма берсе дә аны җылытырга теләмәгән.

Иң соңыннан ул Төлкегә киткән. Төлке:

— Бик ярдәм итәр идем, тунымны да биреп торыр идем, тик кыш буена йоклап ятып, көя күбәләгеннән ашатырсың, дип куркам, — дигән.

Шуннан соң Керпе:

— Энәләрем, кире үземә кайтыгыз, — дигән.

Керпенең барлык энәләре дә үзенә кайткан.

Шуннан соң бөтен хайваннар да Керпене үзләренә кунакка чакыра башлаганнар. Тик Керпе риза булмаган.

Ул әле дә берәүдән дә курыкмыйча яши бирә. Куркыныч килгәндә бүтән җанварлар кебек качмый. Энәләрен тырпайтып бөгәрләнеп ята гына икән.

ЭЧТӘЛЕК

Яктылык ничек тарала 3
Бөдеркәй 7
Алтынкай 19
Ак ромашка 33
Керпе нигә курыкмый? 40

Сәмига Сәүбанова

С93 Яктылык ничек тарала: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 39 бит.

ISBN 5 — 298 — 00887 — 9

Язучының балалар өчен язылган бу әкиятләрендә яхшылык белән яманлыкның көрәше сурәтләнә. Андагы геройлар яхшылыкның һәрвакыт җиңеп чыгуын раслыйлар.

С $\frac{4803560201-087}{М132(03)-97}$ 76—97

ББК 84(Р-Тат)-5

Издание для детей и юношества

Самига Саубанова

(Саубанова Самига Агелтдиновна)

КУДА УХОДИТ СВЕТ?

(на татарском языке)

ИБ № 6782

Редакторы *Р. Заһидуллина*
Бизәлеш редакторы *Р. Шәмсетдинов*
Техник редакторы *Ф. Кәбирова*
Корректоры *Г. Хәбибуллина*

Җыярга тапшырылды 30.09.97. Басарга кул куелды 9.11.97. Форматы 60 × 90 1/16.
Типогр. кәгазе № 2. "Тат.-Кудряшов" гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 2,5. Шартлы буяу-оттиск 6,0. Нәшер-хисап табагы 1,72.
Тиражы 5000 экз. Заказ Ф-57.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан Республикасы информация һәм матбугат министрлыгының
"Полиграфия-нәшер комбинаты" берләштерелгән Дәүләт предприятиесе
420503, Казан, Бауман ур., 19.